СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**14 март 2017 ел.** **№ 49**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Кәче авылында ГРШП техник җиһазлау» «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ линияле объектын төзү территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы уставы, Арча муниципаль районы Советының 2008 елның 27 декабрендәге 220 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районында гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Кәче авылында ГРШП техник җиһазлау» «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ линияле объектын төзү территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга (1 нче кушымта):

2. Билгеләргә:

2.1. Гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 15.04.2017 ел, 12.00 сәгатьтә;

2.2. Үткәрү урыны - Арча муниципаль районы башкарма комитеты бинасы, адресы буенча: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт;

2.3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр тапшырылырга,гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирелергә мөмкин булган адрес: ТР, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт (эш көннәрендә – 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.4. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен заявкалар бирү срогы - 2017 елның 14 апреленә кадәр (тел. 3-12-44).

3. Арча муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм карарның билгеләнгән тәртибенә туры китереп, билгеләнгән срокларда үткәрергә.

4. Әлеге карарны .2017 елның 15 мартына кадәр Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

(http:pravo.tatarstan.ru) Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Муниципаль район башлыгы урынбасары Л.М. Осина